**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**

Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2021 елның « 21» апреленнән № 8-64

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 28.12.2018 ел, № 44-260 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы»муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 28.12.2018 ел, № 44-260 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы»муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

12 статьяның 3 абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Җирлекнең генераль планына, шәһәр округының генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителү белән бәйле җәмәгатьчелек фикер алышулары яки гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында» htt:/pravo. tatarstan. ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru батырып чыгарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллеге органнары белән үзара хезмәттәшлек итү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләнә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы В. М. Козлов